ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге
Тарих институты

*Тууына 500 ел
тулу уңае белән*

# СӨЕМБИКӘ
# ХАНБИКӘ



Сөембикә – татар халкы тарихында онытылмаслык тирән эз калдырган шәхесләребезнең берсе. Ул – милли азатлык һәм мөстәкыйльлек символы. Хатын-кызларга хас гүзәллек сыйфатларын, милли гореф-гадәтләргә тугрылык, туган илгә булган чиксез мәхәббәт хисләрен үзенә туплаган шәхес. Сөембикә татар халкы өчен генә түгел, бөтен төрки дөнья өчен якын. Ничә гасырлар үтүгә карамастан, халык аны әле һаман да онытмый, күңелендә саклый һәм юксына.

Сөембикәнең туган җире – Нугай урдасы, XV йөз башында Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән дәүләт. Ул Казан һәм Себер ханлыкларыннан көньякка таба Идел һәм Иртыш елгалары арасындагы далаларның зур өлешен алып тора. Илдә урнашкан тәртип буенча, нугай халкында ханнар булмый. Илдәге иң зур түрә булып бәк исәпләнә. Муса бәкнең олы улы Йосыф Җаек (хәзерге Урал) елгасының көнчыгышындагы җирләрдә морзалык итә. Сөембикә исә – Йосыф морзаның бердәнбер һәм өзелеп яраткан кызы. Аларның нәсел тармагы Идегәй токымына барып тоташа. Тарихи документларда Сөембикәнең туган елы күрсәтелмәү сәбәпле, аның кайчан туган икәнлегенә төгәл җавап юк. Мәшһүр тарихчы, Сөембикә турында махсус хезмәт язган Һади Атласи ханбикәнең туган елы да, үлгән елы



*Искәндәр Рәфыйков. Сөембикә тәхеттә. 1999*

да билгеле түгел дип, бернинди дә дата күрсәтми. «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә 1516 ел күрсәтелә. Фольклорчы галим, профессор Фатих Урманче Сөембикәне 1519–1520 еллар тирәсендә туган дигән фикердә тора. Күренекле мәгърифәтче, дин белгече, энциклопедист галим Ризаэтдин Фәхретдин хезмәтләрендә 1519 ел күрсәтелә, әлеге датаны күпчелек галимнәр дөрес дип саный.

Аның исеменә килгәндә, кулланышта төрле язылыш йөри: «Сөенбикә» һәм «Сөембикә». Бүгенге көндә күбесенчә «Сөембикә» формасы кулланыла. Һади Атласи, аның исеме елъязмаларда төрлечә язылып, аны кайсылары «Сөен-бик», кайсылары «Сөем-бек», кайсылары «Самбик», кайсылары «Сөмөек», кайсылары «Сөен-бук» дип йөртәләр, ди. Үзе исә, кызның чын исеме «Сөен-бикә» булып, калганнары шуңардан бозылган булырга кирәк, дип исәпли.

Сабыйлык һәм үсмерлек елларын киң дала-кырларда, иркен табигать кочагында уздырган Сөембикә азатлык сөючән, горур, кырыс, бик акыллы, тугры сүзле шәхес булып җитлегә. Үзенең гүзәллеге һәм сылулыгы белән тирә-якта дан тота, мөлаемлыгы, эчкерсезлеге белән кешеләрне үзенә тартып тора. Сөембикәгә багышланган күпсанлы хезмәтләрдә, шул исәптән рус елъязмаларында да, иң беренче чиратта ханбикәнең әйтеп бетергесез гүзәллегенә мәдхия җырлана. *«Сөенбикә чиктән тыш матур һәм сөйкемле вә шуның илә бәрабәр бик акыллы бер кыз була. Нугай кызлары арасында Сөен-бикәгә охшаган кыз булмаган кеби, Казан һәм рус йортларында да аңа тиңдәш булырлык кыз юк иде. Ул көн якның иркен җәйләүләре илә аның мөлаем һавасында тәрбияләнеп үскән вә шуның илә бәрабәр тумыштан матур булганлыгы өчен, дөньяның беренче сөйкемлесе иде*», – диелә тарихи әсәрләрдә. Шуның өстенә, морза гаиләсендә тәрбияләнеп үскән кыз әби-бабадан калган, һәрвакыт изге дип саналган гореф-гадәтләрне, ил йолаларын яхшы белә, аларны җиренә җиткереп үтәргә тырыша.

Сөембикә бик яшьли, 1533 елда, Казан ханы Җангалигә кияүгә бирелә. Тарихи хезмәтләр әлеге никахның мәхәббәт нигезендә түгел, ә һәръякның үз сәяси мәнфәгатьләрен күз алдында тотып корылган булуына ишарә итәләр.

Җангали рәсми рәвештә Казан ханы булып саналса да, чынбарлыкта ирекле булмый. Ул, хөкүмәт башында торучы Мәскәү тараф-



*Билгесез рәссам.*
*Сөембикә ханбикә улы*
*Үтәмешгәрәй белән.*
*Парсуна. XVII йөз башы.*



*Фиринат Халиков.*
*Сөембикә һәм Үтәмеш.*
*2007*

дарлары, Гәүһәршад һәм аның яраннары Булат Ширин белән Табай тырышлыклары аркасында тәхеткә утыртылган хан һәм ханлык белән, нигездә, алар идарә итә. Җангали тәхеткә килгәч, Казан ханлыгы өстеннән яңадан Мәскәү протектораты торгызыла. Шәһәрдә рус хәрби отрядлары урнаша, ханлыкның барлык эшләре бөек кенәз күзәтүе астына алына. Ханлык эчендә урнашкан мондый бәйлелектән халык һич тә канәгать булмый. Шул ук вакытта, Гәүһәршад һәм аның яраннары Мәскәү белән дуслык урнаштыру яклы булсалар да, алар да илнең мөстәкыйльлеге һәм ханлыкта рус йогынтысын чикләү турында хыялланалар. Нәтиҗәдә, 1535 елның 25 сентябрендә Иске Казанда Җангали үтерелә, шулай итеп, Сөембикә тол кала.

Җангалинең үлеменнән соң Казан тәхетенә икенче мәртәбә Кырымнан Сафагәрәй утыртыла. Илдә күптән урнашкан йола буенча, яңа хан вафат булган ханның тәхетенә һәм иленә генә түгел, хатынына һәм балаларына да хуҗа булырга тиеш була. Шулай итеп, Сөембикә Сафагәрәйгә димләнә. Риваятьләр буенча, Сөембикә белән Сафагәрәйнең мәхәббәте беренче күрүдән үк башлана һәм соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. 1546 елда аларның уллары Үтәмешгәрәй туа.

Җангалидән аермалы буларак, Сафагәрәй Казан ханлыгында үзен чын хуҗа итеп күрсәтә, эчке сәясәттә дә, тышкы сәясәттә дә ирекле ханнарча эш итә. Ханлык эчендә үзенә тугры фикердәшләренә таянырга тырыша һәм үз тирәсенә Кырымнан чыккан кешеләрне туплый. Рус җирләренә яу чаба, күп кенә шәһәр һәм авылларны туздыра, кешеләрен әсирлеккә ала, мал-мөлкәтләрен талый. Җыелган байлыкны Кырымга озатып бара. Баштагы елларда тышкы сәяси уңышлар эчке каршылыкларны җиңеп килсәләр дә, тиздән мондый сәясәт Казан түрәләре арасында ризасызлык уята һәм ханга каршы астыртын көрәш башлана.

1541 елның язында ханга каршы чыгучылар рус хөкүмәте белән ханны тәхеттән төшерү турында яшерен сөйләшүләр алып бара башлый. Мәскәүдән Казан өстенә гаскәр җибәрүен үтенәләр. Бу хәлләр Сафагәрәйнең абыйсы, Кырым ханы Сәхибгәрәйгә ишетелә һәм, аның Мәскәүгә каршы сугыш башлавы нәтиҗәсендә, туктатыла.

Яңа күтәрелеш 1545 елда башлана. Казан түрәләре яңадан Иван IVкә мөрәҗәгать итеп, аның кичекмәстән Казанга яу белән килүен

үтенәләр. Русларның ни сәбәпле Казанга яу килүләре Сафагәрәйгә беленә һәм аның үзенә карата булган мондый мөнәсәбәткә бик нык ачуы чыга. Казан ханлыгын сатарга тырышкан күп кеше үлем җәзасына тартыла, күпчелеге качып котыла. Ханның мондый адымы ханлык эчендә тагын да ныграк буталчыклык тудыра, нәтиҗәдә, 1946 елның гыйнварында Сафагәрәй Казаннан качып китәргә мәҗбүр була. Сөембикә исә атасы янына, Нугай Урдасына китә.

Тиздән, Сафагәрәй яхшы коралланган нугай гаскәре белән Казанга кайта һәм тәхеткә утыра. Сөембикә дә хан сараена кайтарыла.

Сафагәрәй эчке сәясәтен тагын да кискенрәк рәвештә дәвам итә: ханлык эчендә үзенә каршы булган барлык кешеләрне үлем җәзасына тарта, җирле түрәләрне кыерсыта, иң мөһим дәүләт урыннарына Кырым кешеләрен билгели. Күп кенә түрәләр һәм сугышчылар ханлыктан чыгып кача. Шулай итеп, ханлык эчендә көч белән ирешелгән бердәмлек урнаша.

1549 елның мартында Сафагәрәй кинәт үлеп китә, Сөембикә ике яшьлек улы белән янәдән тол кала. Аның өчен гомеренең иң авыр еллары башлана.



*Ильяс Фәйзуллин. Илчеләр Казан ханбикәсе Сөембикә янында. 2000*



*Нияз Хаҗиәхмәтов. Сөембикәнең Сафагәрәй кабере белән хушлашуы. 2003*

Сафагәрәй вафатыннан соң көн тәртибенә тәхет варисы мәсьәләсе килеп баса. Аның төрле хатыннардан өч өлкән һәм бер сабый улы була. Ике балигъ шаһзадә, Мөбәрәкгәрәй һәм Бүләкгәрәй, Кырымда Сәхибгәрәй хан сараенда яшиләр. Тагын берсе – рус кәнизәгеннән туган улы – хан тәхетен дәгъвалау хокукыннан мәхрүм була. Иң кечесе – Үтәмешгәрәй.

Хан тәхетенә сабый бала Үтәмешгәрәй утыртыла. Ул үсеп балигъ булганчы аның исеменнән дәүләт белән Сөембикә идарә итәргә тиеш була. Ханлыкта яңа хөкүмәт төзелә. Аның төп өлешен элеккеге кебек үк кырымлылар тәшкил итә. Хөкүмәт башлыгы итеп Кырымнан килгән хан гвардиясе башлыгы – Кошчак Бәк углан билгеләнә. Хөкүмәт даирәләрендә тышкы сәясәт буенча тагын берничә төркем барлыкка килә. Берсе, Мәскәү тарафдарлары – алар рус дәүләте белән тынычлык төзеп, тәхеткә Мәскәү тәкъдим иткән ханны кабул итәргә риза булалар. Икенчеләре, Көнчыгыш тарафдарлары – болары мөселман илләренең ярдәменә өмет итәләр. Ахыргылары җиңеп чыга, ә беренчеләре Казанны ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Ханлык эчендәге чуалышлардан һәм аның көчсезләнүеннән файдаланып, Иван IV ике мәртәбә Үтәмешгәрәй һәм Сөембикә хөкүмәтенә каршы

һөҗүм ясый. Ике якта да бик күп югалтулар була, ләкин бу һөҗүмнәр Иван IVкә җиңү китерми. Соңгы, 1550 елгы, сугыштан соң Казан ханлыгы бер ел тыныч яши.

Алдагы уңышсызлыкларыннан соң, Иван IV барлык көчен куеп хәлиткеч яуга әзерләнә башлый. Казан ханлыгына илтә торган елга юллары киселә, армиянең сугышчан сәләтен күтәрү өчен 1551 елның язында Зөя елгасы тамагында хәрби ныгытма төзелә, тау ягы халыкларына патша хөкүмәте ягына чыгарга мәҗбүр итә торган шартлар тудырыла. Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә Казан чолганышта кала, ханлыкның зур гына мәйданы Мәскәү кул астына күчә.

Сөембикә хакимиятенең хәле һаман катлаулана бара. Ханлыкны шушы дәрәҗәгә төшергән яңа хөкүмәткә карата мөнәсәбәт тагын да киеренкеләнә, нәтиҗәдә, бертөркем кырымлы, шул исәптән Кошчак углан да, төнлә Казаннан чыгып качарга мәҗбүр булалар. Юлда алар рус гаскәре тарафыннан кулга алына, һәм исән калган 46 кеше, Мәскәүгә озатылып, җәзалап үтерелә. Сафагәрәйнең һәм Сөембикәнең терәге булган кырымлыларның язмышы шулай тәгәлләнә. Сөембикә өчен бу олы югалту була. Ул ялгызы кала.

Казанда яңа хөкүмәт сайлана, аның башында Мәскәү яклы кешеләр була. Алар Казанны саклап калу максатыннан Мәскәү белән солых төзиләр. Аның төп шартлары:

- Үтәмешгәрәй ханны һәм аның әнисе Сөембикәне Мәскәүгә «шөһрәтле тоткынлыкка» озатырга;
- шәһәрдә булган барлык рус әсирләрен һич кичекмәстән азат итәргә;
- шәһәрдә калган кырымлыларны Мәскәү патшасына тапшырырга;
- Казан ханы итеп тәхеткә Шаһгалине утыртырга.

Риваятьләр буенча, юлга әзерләнү өчен Сөембикәгә ун көн вакыт бирелә. Ун көн буе ул каты сак астында тора. Казанны мәңгегә калдырып китәр алдыннан Сөембикәгә ире Сафагәрәй кабере белән хушлашырга рөхсәт ителә. Ул ире кабере янында күз яшьләрен тыя алмыйча, сулкылдап елый. Һуштан язып егылган ханбикәне кабер янын-

нан күтәреп алып китәләр. Соңыннан әлеге ханнар каберлеге янында Сөембикә манарасы калкып чыга.

Юлның ике ягына тезелгән халык сөекле ханбикәсен күз яшьләре белән озатып кала. Сөембикәне акыллы, бик юмарт һәм һәрбер кешегә мәрхәмәтле булганы өчен, халык ярата һәм хөрмәт итә. Шулай итеп, Сөембикә, беренчедән, Казан ханлыгының мөстәкыйльлеген саклап калу нияте белән һәм, икенчедән, тәхет өчен тарткалашкан төрле сәяси төркемнәрнең теләкләрен үтәп, 1551 елның 11 августында улы Үтәмешгәрәй белән Мәскәүгә әсирлеккә китәргә мәҗбүр була. 5 сентябрьдә аларны Мәскәүгә китереп җиткерәләр.

Сөембикә Казанда 18 ел яши. Шушы вакыт эчендә ул Казан халкы күңелендә якты эз калдыра. Һади Атласи сүзләренә караганда, Сөембикә Казаннан киткәч, *«...озак елларга чаклы Казан кешеләренең күзләреннән яшьләре кипмәде. Казан халкы һәрвакыт Сөен-бикәне искә төшерә, аны сагынадыр иде. Чынлап та, Сөен-бикә сагынырлык хатын иде. Казанның борынгы падишаһлары ханлыкның кайсыдыр сыйныфларын алда тоталар, үзләренең күбрәк багышлауларын шуларга гына багышлыйлар, халыкның күбрәген исә коры калдыралар иде. Сөен-бикә исә алай булмады. Ул, Казан олугъларыны дәрәҗәләренә карап баглады-*



*Фиринат Халиков. Казан белән хушлашу. 2001*



*Ильяс Фәйзуллин. Казан ханбикәсе Сөембикә Явыз Иванда әсирлектә. 2001*



*Василий Худяков. Тоткынлыкка төшкән Сөембикәнең Казаннан китүе. 1870*

*гы кеби, Казанның урта һәм түбән дәрәҗәдәгеләрене дә онытмыйдыр, һәркайсына үзенең сыеннан өлеш чыгарадыр иде. Аның шушы эшләре Казан халкының күңеленә бик нык урнашкан булганлыгы өчен, алар Сөен-бикәне тиз генә оныта алмадылар... Ул үзе күңелләрдә калдыгы кеби, аның исеме дә телләрдә калды».*

Казан ханлыгының мөстәкыйльлеген саклап калу өчен куелган тырышлыклар бушка китә. 1552 елның 2 октябрендә Иван IV гаскәре яу белән Казанны ала. Казан ханлыгы яшәүдән туктый.

Сөембикә исә, Казаннан китеп ел ярым вакыт узганнан соң, Шаһгалигә көчләп кияүгә бирелә һәм Касыйм шәһәренә озатыла. Ул Кырым династиясе вәкилен тугрылыклы Касыйм ханына кияүгә биреп, Сөембикәне һәм Үтәмешгәрәйне хан тәхетенә дәгъва итүдән читләштерү мөмкинлеген күздә тота.

Сөембикәне Казаннан алып киткәннән соң, әтисе – Йосыф бәк – Иван IVкә кызын һәм оныгы Үтәмешгәрәйне тоткынлыктан азат итеп, туган иленә кайтарып җибәрүен үтенеп ярлыклар җибәрә. Әмма аның үтенечләре кире кагыла, патша Сөембикәнең яхшы тормышта яшәве, үзе теләп Шаһгалигә кияүгә чыгуы турында уйдырма җаваплар юллый.

Үтәмешгәрәй әнисеннән аерылып, Мәскәүдә кала. Сабый 1553 елда Чудово чиркәвендә чукындырыла. Аңа Александр дип исем кушыла. Алга таба ул патша сараенда христиан рухында тәрбияләнә. Үтәмеш-Александр озак яшәми: 1566 елның 11 июнендә 20 яше тулар-тулмас вафат була.

Тарих битләрендә Сөембикә турында хәбәрләр 1554 елдан соң киселә. Әмма аның кайда һәм ничек үлүе билгеле түгел. Берәүләр, Сөембикәнең 1554 елда Касыйм шәһәрендә вафат булуын фараз кыла. Икенчеләр фикеренчә, ул 1557 елда, 38 яшьләр тирәсендә, дөньядан китә. Ханбикәнең кайда күмелүе билгеле түгел. Анын кабере Касыйм шәһәрендәге ханнар төрбәсендә булырга мөмкин.

Сөембикә дәүләт өчен катлаулы чорда ил язмышын үз кулына алырга мәҗбүр булган, милләт бәйсезлеген саклап калу өчен үзен һәм газиз сабыен корбан иткән бөек шәхесләребезнең берсе. Аның авыр язмышы шәхси фаҗигасе генә булып калмый, бөтен татар халкы, татар милләте фаҗигасенә әверелә. Ул бүген дә каһарманлык, ватанпәрвәрлек, иманга тугрылык символы буларак халык күңелендә саклана.

## Әдәбият


Атласи Һ. Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

Илгаз Ваһап Нәүрүзхан. Сөембикә (тарихи роман). – Казан: «Милләт» нәшр., 2019.

История татар с древнейших времен. В семи томах. Т. IV. Татарские государства XV–XVIII вв. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2014.

Сююмбике=Сөембикә: альбом / авт. текста Р.Г. Шагеева. – Казан: Татар. кн. изд-во, 2017.

Урманче Ф. Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – М.: ИНСАН, Совет по сохранению и развитию культур малых народов, СФК, 1991.

Хуҗин Ф. Кол Гали. Кол Шәриф. Сөембикә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.



*А.Ә. Зиннәтуллина, М.М. Гибатдинов* тексты

Рәсемнәр интернет челтәреннән алынды

Тышлыкта: *Булат Гыйльванов. Сөембикә һәм Бәрәҗ. 2010*

*Л.М. Җиһангәрәева* оригинал-макеты

ТР ФАның Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтында әзерләнде

420111 Казан, Батурин ур., 7А

Казан 2019